**Бишек җыры «Әнием»**

Тәмле йокылар теләп
Чәчләремнән ул назлый,
Укыган догалары
Минем йокымны саклый.

Кушымта:
Миңа һәрчак булыша ул
Мин бит әле бик нәни,
Кем дисезме?,-Ул әлбәттә
Әлбәттә минем Әни!

Әнкәемнең кочагы
Иңдерә иман нуры,
Куңелгә сафлык өсти
Яктыра гомер юлы.

Кушымта:
Миңа һәрчак булыша ул
Мин бит әле бик нәни,
Кем дисезме?,- Ул әлбәттә
Әлбәттә минем Әни!